**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» июня 2019 с. Тюлячи № 367

Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетларының баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131нче номерлы Федераль закон нигезендә Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган:

1.1. Теләче муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм шартлары турында нигезләмәне.

1.2. Теләче муниципаль районы муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәне расларга.

2. Хезмәткәрләрнең әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме саклангнда һәм алар тарафыннан шул ук квалификациядәге эшләр башкарылганда, 2019нчы елның 31нче мартына түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестицион эшчәнлек буенча урынбасары И.Ә. Миннигуловка:

3.1. Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) вазыйфаларын әлеге карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

3.2. Әлеге карарның үтәлешенә контроль урнаштырырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2019нчы елның 1нче апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 18 июненең 367
санлы карары белән расланган

Нигезләмә
Теләче муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм шартлары турында

1. Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен билгели.

2. Теләче муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакы вазыйфаи хезмәт хакыннан, тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына ай саен өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен өстәмә түләүдән, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәм һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләүләрдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрләрдән тора.

3. Теләче муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи хезмәт хакы , сумнарда<br>Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 23700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 21500 |
| Бүлек начальнигы | 17700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 15300 |
| Бухгалтер | 14000 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкчесе урынбасары вазыйфасын кертү өчен структурада һәрберсендә кимендә 5 штат берәмлеге булган 3 бүлек булуы шарт.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләрендә кимендә 5 штат берәмлеге булырга тиеш.

4. Теләче муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә билгеләнә:

1) Тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түбәндәге күләмнәрдә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан күбрәк | 15 |

2) Вазыйфаи хезмәт хакының 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә.

3) Еллык түләүле ял биргәндә елга бер тапкыр вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә түләү.

Әгәр хезмәткәргә календарь елы дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә түләнә, эштән азат ителгән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Беренче эш елында еллык түләүле ял биргәндә, хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә исәпләнә.

4) Билгеләнгән хезмәт хакыфонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм.

5) Билгеләнгәнхезмәт хакы фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премия (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми).

5. Теләче муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләренең еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT=\sum((Od+0{,}3*Od)n1*k)*(1+t)+\sum Pn1*(1+t);$$

монда:

$FOT$ –җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды;

$Od$ –җитәкче һәм белгечнең айлык вазыйфаи хезмәт хакын түләү өчен акча суммасы;

$0{,}3*Od$ – тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен, акчалата бүләкләү,еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләнәторган түләү, матди ярдәм өчен акча суммасы;

P – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык премиаль фонды (әлеге Нигезләмәнең 4 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә);

$n$ – җитәкчеләр һәм белгечләрнең штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт хакы түләү өчен исәпләү.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 18 июнендәге 367
санлы карары белән расланган

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында (Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) турында
Нигезләмә

1. Теләче муниципаль районы муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) (алга таба – бухгалтерларның) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы әлеге Нигезләмә бухгалтерлар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хакларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи хезмәт хакыннан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына ай саен өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен өстәмә түләүдән, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәмнән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. Бухгалтерларның вазыйфаи хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән күбрәк |
| Баш бухгалтер | | 17000 |
| Бухгалтер | 14500 | 14500 |

4. Бухгалтерларга билгеләнә:

1) Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түбәндәге күләмдә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан күбрәк | 15 |

2) Вазыйфаи хезмәт хакының 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә.

3) Еллык түләүле ял биргәндә елына вазыйфаи хезмәт хакының 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Әгәр бухгалтерларга календарь елы дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләгән вакыт өчен пропорциональ рәвештә түләнә, эштән азат ителгән очракта, соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Беренче эш елында еллык түләүле ял биргәндә,бухгалтерларга бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы календарь елының 31 декабренә исәпләнә.

4) Билгеләнгән хезмәт хакы фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм.

5) Билгеләнгән хезмәт хакы фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премия (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми).

4. Бухгалтерларныңеллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT=\sum((Od+0,3*Od)n1*k)*(1+t)+\sum Pn1*(1+t);$$

монда:

$FOT$ – бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды;

$Od$ – бухгалтерларныңайлык вазыйфаи хезмәт хакын түләү өчен акча суммасы;

$0,3*Od$ – тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен өстәмә түләү, акчалата бүләкләү,еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү, матди ярдәм өчен акча суммасы;

$P$ – бухгалтерларның еллык премиаль фонды (әлеге Нигезләмәнең 4 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә);

$n$ – бухгалтерларнын штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт хакы түләү өчен исәпләү.